# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

(V чакырылыш)

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

«24» декабрь 2025 ел № 21 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 25.04.2018 ел № 11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы депутатларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"гы 28.03.2018 ел, № 182 карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы 14.04.2025 ел, № 228 карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 25.04.2018 № 11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы депутатларына, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 1 пунктында "15 389" саннарын "16928" саннарына алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.3. Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә элек кабул ителгән хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Сучкова А.В.
8(85593)2-80-12

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2025 елның "24" декабрендәге 21 санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгын, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарын, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларын, сайланулы вазыйфаи затларын, контроль-хисап органы рәисен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 44 814 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 40 334 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 40 334 |

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2025 елның "24" декабрендәге 21 санлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шәһәр тибындагы бистәләр нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләрендә | | | |
| | 9 төркем | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 31 496 | 27 601 | 25 401 | 23 201 |